# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

## К А Р А Р

24 ноябрь 2019 ел № 59/3

**2019 елның 24 ноябрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай районы территориаль сайлау комиссиясе 2019 елның 24 ноябрендә тавыш бирү нәтиҗәләре турында участок комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәсе мәгълүматлары нигезендә 2019 елның 24 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде, аның буенча:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлану мизгеленә **729** референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучылар саны – **412**, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларның **56,52 %**ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен **367** референдумда катнашучы тавыш бирде, бу тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучыларның **89,08 %**ын тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен **45** референдумда катнашучы тавыш бирде, бу **10,92%** тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясе карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге территориясендә референдум узган, референдум нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

«Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2018 елның 18 ноябрендә уздырылган референдум нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карар нигезендә авыл җирлеге бюджетына кергән Мусабай-Завод авылында янгын сүндерү депосы төзелешенә билгеләнгән гражданнарның калган үзара салым акчасын Мусабай-Завод авылы зиратында койма сатып алып урнаштыру; Ташкичү, Мусабай-Завод һәм Кызыл Байрак авылларында урамнар яктырткычларын төзекләндерү өчен файдалануга ризамы», кабул ителгән.

2. Җирле референдум нәтиҗәләрен «Якты Юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
территориаль сайлау
комиссиясе рәисе _____________ С.Р. Дәүләтшина
имза

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
территориаль сайлау
комиссиясе секретаре _____________ Э.Н. Гайфуллина
имза